Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Габдрахман авыл Советы

КАРАРЫ

14 декабрь 2023 ел №104

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Габдрахман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 27 декабрендәге 48 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон 15 статьясы 4 өлеше,Әлмәт муниципаль районының «Габдрахман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан торак пунктларга тапшыру турында» 2022 елның 12 декабрендәге 182 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, Әлмәт муниципаль районы башлыгының 2022 елның 23 августындагы 148 номерлы карары нигезендә узган «Гавами тыңлаулар билгеләү турында» 2023 елның 20 сентябрендәге 8159и номерлы ( «Альметьевский вестник» газетасының 2023 елның 21 сентябрендәге 39 номерлы санында басылган) гавами тыңлаулар нәтиҗәләре бәяләмәсе нигезендә,

Габдрахман авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Габдрахман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 27 декабрендәге 48 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарына (2022 елның 11 маендагы 45 номерлы, 2022 елның 26 сентябрендәге 58 номерлы, 2023 елның 24 апрелендәге 81 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1 статьяның 12 абзацында «төзүчеләрнең бөлгенлеге (банкротлыгы) аркасында өлешле төзелештә катнашучыларның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-

хокукый компаниясе» сүзләренә алмаштырырга;

- 4 статья 4 пунктчасының 9 абзацында икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

- 19 статья 2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җир асты байлыкларыннан файдалануны гамәлгә ашыру.»;


19 статьяның 3 пунктында «Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 1, 3 һәм 4 пунктчаларында каралган максатларда гавами сервитут чикләре» сүзләрен «Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 1, 3 һәм 4.1 пунктчаларында каралган максатларда, шулай ук Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 6 пунктчасы нигезендә инженерлык корылмалары кишәрлекләрен (өлешләрен) реконструкцияләү максатларында билгеләнә торган гавами сервитут чикләре» сүзләренә алмаштырырга;

- 19 статьяның 4 пункты 1 пунктчасында «1, 3 һәм 4 пунктчаларында» сүзләрен «1,3 һәм 4.1 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга.


- 27 статьяның 7 пункты 19 абзацында «туфракны ашлау өчен агып төшүче сулардан файдалану» сүзләрен «туфракның уңдырышлылыгын арттыру максатларында агып төшүче сулардан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны урнаштыруның территориаль зонасын киметү, кадастр номеры 16:07:090103:118 булган җир участогына карата шәхси торак йортлар белән төзелешнең территориаль зонасын арттыру өлешендә Габдрахман авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә:

Гамәлдәге торышы




Проектта каралу




2.Әлеге карарны торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Габдрахман авылы, Совет урамы, 77 йорт, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Габдрахман авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Габдрахман авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Мифтахов